ГЛАВА
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

2024 елның «05» мартыннан　　　　　　　　　　　　№ 11

«2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисапны раслау хакындагы проект буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2019 елның 24 октябрендәге 53-325 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмә»се, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә»се нигезендә, «2023 елгы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисапны раслау хакындагы проект буенча фикер алышуда катнашу өчен Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында яшәүчеләрнең хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. 2023 елның 20 мартында 17:00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80нче йорт адресы буенча Яңа Чишмә муниципаль районы Советының кече актлар залында «2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисабын раслау хакында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

Ачык тыңлаулар тәртибе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябреннән14-105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы 2021елның 12 октябрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырылган нигезләмәгә туры китереп тормышка ашырыла.

2. «2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисапны раслау хакында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисабын раслау хакында» карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздыруны, гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә һәм 2024 елның 22 мартына кадәр ачык тыңлаулар беркетмәсен тапшырырга.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының Бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә «2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисабын раслау хакында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектын, ачык тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм 2024 елның 25 мартына кадәр Яңа Чишмә муниципаль районы Советы утырышында карауга кертергә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә

муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Башлык В.М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2024 елның «05» мартыннан
11 номерлы карарына
кушымта

«2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисапны раслау хакында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе

1. «2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты үтәлеше турында» хисабын раслау хакында карар проектына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Совет урамы, 80 йорт, каб. № 314 язма рәвештә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге җитәкчесенә тапшырыла.

Тәкъдимнәр «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http: //pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырылган көннән алып, эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 нче йорт, каб. № 314 шәхсән яки почта аша (конвертта«Бюджет турында фикер алышу» тамгасы беләя).